| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ КУРНАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КӨРНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

с.Сухие Курнали

01.07.2026 № 23

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проекты хакында**

Идел буе транспорт Прокуратурасының 01.06.2026 ел №23/1-2-2026 протестын, Алексеевск районы прокуратурасының 13.04.2026 ел №02-01-16 бәяләмәсен үтәү йөзеннән «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел № 33-ФЗ Федераль законның 16 статьясына туры китереп» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ**

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Көрнәле авыл җирлеге Советының 10.08.2023 ел, № 51 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә, түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

1) 38 статьяның 2 өлешендәге 5 пунктында «һәм тимер юл транспортының контакт челтәрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 56 статьяның 1 өлешендә «тимер юл транспортының контакт челтәре таянычлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 56 статьяның 4 өлешендә «һәм тимер юл транспортының контакт челтәре таянычларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 79 статьяның 4 өлешендәге 4 пунктында «4) торак массивлар, җәмәгать урыннары һәм социаль объектлар территориясендә хуҗалары булмаган хайваннарны ашату. Искәрмә – тыю җирле үзидарә органы тарафыннан хуҗасыз хайваннарны ашату өчен махсус оештырылган урыннарга кагылмый» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуын расларга (1 нче кушымта).

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибен һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашуын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), шулай ук әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: Башкарма комитетның административ бинасы (Коры Көрнәле авылы, Зәки Кутлин урамы, 24 йорт).

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Казакова Д.Б. – Көрнәле авыл җирлеге Советы рәисе.

2) Вәлиев Т.Н. – 6 нчы Көрнәле сайлау округы депутаты.

3) Фәтхуллин С.С. – 1 нче Көрнәле сайлау округы депутаты.

4) Казаков Р.М. – 5 нче Көрнәле сайлау округы депутаты.

6. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутатларының Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына тәкъдимнәре төзәтмәләр рәвешендә эшче төркемгә 2026 елның 21 июленә кадәр кертелә дип билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына гражданнарның тәкъдимнәре, Ф.И.А., туган елы,авторның адресы күрсәтелеп язма рәвештә түбәндәге: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Коры Көрнәле авылы, Зәки Кутлин урамы, 24 йорт адресына җибәрелә дип билгеләргә.

8. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр проекты буенча 21.07.2026 елда 10.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар билгеләргә: Татарстан Республикасы Алексеевск районы, Коры Көрнәле авылы, Зәки Кутлин урамы, 24 йорт.

9. Эшче төркемгә Көрнәле авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектына гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнеп һәм гомумиләштереп, аны 23.07.2026 елга кадәр Көрнәле авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Көрнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Д.Б. Казакова**

Көрнәле авыл җирлеге
Советының 01.07.2026 ел, № 23
карарына 1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Совет карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу**
**ТӘРТИБЕ**

1.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Совет карары проектына тәкъдимнәр Көрнәле авыл җирлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Коры Көрнәле авылы, Зәки Кутлин урамы, 24 йорт, язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф. И. А., адресы, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар уздырылырга 7 көн кала кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен чыгыш ясау хокукы белән, гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Коры Көрнәле авылы, Зәки Кутлин урамы, 24 йорт, язма рәвештә шәхсән яисә почта аша.

Гаризалар эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр кабул ителә

3. Гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркем тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына һәм Башлыгына тапшырыла.

Көрнәле авыл җирлеге
Советының 01.07.2026 ел,
№ 23 карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының « Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Совет карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү**

**ТӘРТИБЕ**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» Совет карары проектын карау буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, прокуратура, белгечләр, сәяси партияләр, башка иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен, белгечләрне, кызыксынган затларны чакырып үткәрелергә мөмкин.

3. Гавами тыңлауларда Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

5. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 10.08.2023 ел, №51 Совет карарына үзгәрешләр кертү проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча гавами тыңлауларда рәислек итүче булып эшче төркем җитәкчесе- Көрнәле авыл җирлеге Советы рәисе Д. Б. Казакова тора.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул анда катнашучыларга тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен секретариатның җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында гавами тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге «Муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 10.08.2023 ел, №51 Совет карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын эшләү буенча эшче төркем җитәкчесе Көрнәле авыл җирлеге Советы рәисе чыгыш ясый.

9. Төп докладтан соң сүз гавами тыңлауларда катнашу өчен чакырылган катнашучыларга бирелә.

10. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукына ия катнашучылар үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гариза бирү вакытына карап чират тәртибендә чакырылалар.

11. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары расланган регламент нигезендә дәвам итәргә тиеш.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

13. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны бүлдерергә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

14. Гавами тыңлаулар үткәргәндә тәртип саклау гавами тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

15. Гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны тыңлаулар уздырыла торган бинадан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

16. Чыгышлар тәмамлангач, рәислек итүче гавами тыңлаулар барышында әйтелгән искәрмә, тәкъдимнәрне төгәлләштерү өчен оештыру комитеты секретарена сүз бирә ала.

17. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтү һәм тәкъдимнәре гавами тыңлаулар беркетмәсенә кертелә. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә оештыру комитеты рәисе һәм секретаре имза сала һәм Көрнәле авыл җирлеге Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә гавами тыңлаулар секретариаты тарафыннан әзерләнә һәм халыкка җиткерелергә тиеш.

19. Гавами тыңлауларны оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Көрнәле авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.